■ Безгә язалар

# ЯНӘ БЕР ИМАН ДӘРЕСЕ

Гөлнара РӘХМӘТИЕВА,
Балтач районы,
Иске Балтач авылы.



Корбан гаете һәм мөселман өчен иң олы бәйрәм. Яңа Ямурза, авылында бәйрәм үзенчәлекле, күркәм оештырылды. Иртә белән халык ирләр өчен фарыз булган гает намазына ашыкты. Дүрт ел элек ачылган "Фәрит" мәчетендә имам вазифасын башкаручы Фәнис Хәмәтҗан улы Мөхәмәтҗанов дин кардәш-ләрен олуг бәйрәм белән тәбрикләде, вәгазендә мөселманнарны Аллаһының әмер-ләрен үтәп яшәргә өндәде. Намаздан соң Аллаһы ризалыгы өчен 4 корбанлык сарык чалынды һәм табын әзерләнде. Корбан ашын авыз итәргә йөздән артык кеше килде. Коръән мәҗлесе ашау-эчүгә генә бәйле булса, аның төп асылы югала. Пәйгамбәребезнең (сас) сөн-нәте буенча мөселманнар җыелган урында белем алу - иң хәерлесе. Шуңа ерак-якыннардан килгән кунаклар, авылдашлар мәчеткә бирелгән йортның шәҗәрә агачы белән таныштылар. Әтисе вафат булгач Роза Фәрит кызы иптәше Рәфис Фәукать улы Сәлимгәрәев белән туып-үскән йортын мәчеткә бирергә карар итәләр. Динне инкар иткән чорда киселеп, сыкрап ауган мәчет манарасы авыл өстендә янә калкып чыга...

Фәрит Таһир улы гомере буе авыл мәктәбендә физика, математика фәннәрен укыта. Туган җиренә гашыйк кеше архивларда авылдашларының да, үзенең дә нәсел - нәсәбен эзләп барлый. Эдик Кәримов 2009нчы елда төшергән нәсел агачында бүген 400ләп кеше, тугызынчы буынга кадәр вәкилләр бар. Усый, Урсый, Уразгилде, Бикбау, Мөхәмәтдин, Таһир улы Фәрит...

Таһир Мөхәмәтдин улы белән Шәмгыйҗинан Садретдин кызының гаиләсендә 4 бала була. Олысы - Фәридә Иске Балтач мәктәбендә балаларга тарих белемен өйрәтә.

Икенче кызлары Асыя үз алды дини белем алып, дин әһеле вазифаларын үти, халыкны иманга өнди. Ул яратып башкарган мөнәҗәтләрне балалары да отып алган, ә Эльвира Фәнзәви кызы башкаруында яңгырап, алар күңелләргә барып җитте.

Әнисе Шәмгыйҗинанның иңнәренә төшкән авырлыкларны кичереп, берүзе (чөнки әтисе Таһир сугыш кырларында ятып кала) 4 балага тәрбия бирүе турында сөйләде кызы Нәгыймә. Әнисе мәдрәсәдә белем ала, Коръәнне яттан белә. 1897 елда басылып чыккан изге китапны гаиләдә бүген дә укучылар бар. Ачлы-туклы елларда, эссеме, урак өстендәме тиешенчә ураза тота, намаз укый, кардәшләре белән гает бәйрәмнәрен яшерен уздыра Шәмгыйҗинан әби.

Нинди рухи көч булган зур әниләребездә! Аларның догафатихалары белән атеизм кысаларын ерып чыктык.

Нәселдә күбрәк укытучылар, врачлар, сәүдәгәрләр, үз көчләре белән тырышып эшләп яшәүчеләр. Иҗади кешеләр дә аз түгел. Фәйхунә Әхкамованың ("Илһам баскычлары" район конкурсы лауреаты), Зимфирә һәм Хәмәтгали Аскаровларның, Фәрит Таһировның шигырьләре, Әхмәдулла Рәхмәтиевның әсәре яңгырады бәйрәм көнне.

Балалар кешегә амәнәт итеп бирелә. Аларга яхшы тәрбия бирү - ата-ананың бурычы. Иманлы, итәгатьле бала ата-анасына җәннәт ишекләрен ачар, тәмуг утына пәрдә булыр. Шуңа да сабый кыз - Элеонора Зарипованың Коръәннән аятьлар укуы һәммәсенең күзләрен чылатты, күңелләрдә изге тойгылар уятты. Яшь рәссамнәр сурәтләгән иман йортлары да тантананы нурландырды.

Хәзерге вакытта күп кеше кайчандыр бер хәер бирүне, Коръән мәҗлесендә өстәл артында яки мәчеттә генә яулык бәйләп, түбәтәй киеп, дәшмитынмый мулланы тыңлап утыруны мөселманлык билгесе дип уйлый. Дөреслектә, дин - ул яшәеш рәвеше, ул көндәлек тормыштан аерылырга тиеш түгел. Ир заты акыллы һәм гадел хуҗа булса, хатын-кыз балаларга иманлы тәрбия бирсә, Аллаһы кушканын үтәп, тыйганнарыннан тыелып яшәсәләр - иң яхшы яшәеш рәвеше булыр.

Коръәни Кәримдә әйтелгән: "Иң яхшыларыгыз сезнең Коръән укыганнарыгыз һәм дин белемен кешеләргә аңлатучыларыгыз" . Өй җылысы сакланган мәчеттә үткәрелгән мәҗлес - шуңа бер якты мисал. Дини мәҗлесләр савапсыз ашап-эчүгә генә корылмаса, хәергә символик акча өлешү максаты белән үткәрелмәскә иде (сәдака мохтаҗларга бирелергә тиешлеген онытмыйк). Алар иман дәресләре булып үтсен.

## Өфөлә намаҙ ваҡыты

**Мөхәррәм -Сәфәр 2011 миләди йыл**
**1433 һижри йыл.**

| Мөхәррәм, Сәфәр | Аҙна көндәре | Декабрь, Январь | Иртәнге намаҙ | Ҡояш сыға | Өйлә нам. | Икен. нам. | Аҡшам. | Йәстү намаҙы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 16 | Йәкшәмбе | 11 | 9.01 | 10.31 | 14.30 | 16.17 | 17.47 | 19.17 |
| 17 | Дүшәмбе | 12 | 9.02 | 10.32 | 14.30 | 16.17 | 17.47 | 19.17 |
| 18 | Шишәмбе | 13 | 9.03 | 10.33 | 14.30 | 16.17 | 17.47 | 19.17 |
| 19 | Шаршамбы | 14 | 9.04 | 10.34 | 14.30 | 16.16 | 17.46 | 19.16 |
| 20 | Кесе йома | 15 | 9.05 | 10.35 | 14.30 | 16.16 | 17.46 | 19.16 |
| 21 | Йома | 16 | 9.06 | 10.36 | 14.30 | 16.17 | 17.47 | 19.17 |
| 22 | Шәмбе | 17 | 9.07 | 10.37 | 14.30 | 16.17 | 17.47 | 19.17 |
| 23 | Йәкшәмбе | 18 | 9.07 | 10.37 | 14.30 | 16.17 | 17.47 | 19.17 |
| 24 | Дүшәмбе | 19 | 9.08 | 10.38 | 14.30 | 16.17 | 17.47 | 19.17 |
| 25 | Шишәмбе | 20 | 9.09 | 10.39 | 14.30 | 16.18 | 17.48 | 19.18 |
| 26 | Шаршамбы | 21 | 9.09 | 10.39 | 14.30 | 16.18 | 17.48 | 19.18 |
| 27 | Кесе йома | 22 | 9.10 | 10.40 | 14.30 | 16.18 | 17.48 | 19.18 |
| 28 | Йома | 23 | 9.10 | 10.40 | 14.30 | 16.19 | 17.49 | 19.19 |
| 29 | Шәмбе | 24 | 9.11 | 10.41 | 14.30 | 16.20 | 17.50 | 19.20 |
| 30 | Йәкшәмбе | 25 | 9.11 | 10.41 | 14.30 | 16.20 | 17.50 | 19.20 |
| 1 | Дүшәмбе | 26 | 9.11 | 10.41 | 14.30 | 16.21 | 17.51 | 19.21 |
| 2 | Шишәмбе | 27 | 9.12 | 10.42 | 14.30 | 16.22 | 17.52 | 19.22 |
| 3 | Шаршамбы | 28 | 9.12 | 10.42 | 14.30 | 16.23 | 17.53 | 19.23 |
| 4 | Кесе йома | 29 | 9.12 | 10.42 | 14.30 | 16.24 | 17.54 | 19.24 |
| 5 | Йома | 30 | 9.12 | 10.42 | 14.30 | 16.25 | 17.55 | 19.25 |
| 6 | Шәмбе | 31 | 9.12 | 10.42 | 14.30 | 16.26 | 17.56 | 19.26 |
| 7 | Йәкшәмбе | 1 | 9.12 | 10.42 | 14.30 | 16.26 | 17.56 | 19.26 |
| 8 | Дүшәмбе | 2 | 9.12 | 10.42 | 14.30 | 16.28 | 17.58 | 19.28 |
| 9 | Шишәмбе | 3 | 9.11 | 10.41 | 14.30 | 16.29 | 17.59 | 19.29 |
| 10 | Шаршамбы | 4 | 9.11 | 10.41 | 14.30 | 16.30 | 18.00 | 19.30 |
| 11 | Кесе йома | 5 | 9.11 | 10.41 | 14.30 | 16.31 | 18.01 | 19.31 |
| 12 | Йома | 6 | 9.10 | 10.40 | 14.30 | 16.33 | 18.03 | 19.33 |
| 13 | Шәмбе | 7 | 9.10 | 10.40 | 14.30 | 16.34 | 18.04 | 19.34 |
| 14 | Йәкшәмбе | 8 | 9.09 | 10.39 | 14.30 | 16.36 | 18.06 | 19.36 |

# ИЗГЕ ГЫЙБӘДӘТ

Гумәр НАБИУЛЛИН

***"Намаз - диннең баганасы", тигән Пәйгамбәребез (сас). Сезгә, хөрмәтле гәзит укучылар, картатайым сөйләгән бер хикәйәт турасында сөйләп үткем килә.***

Бервакыт бер падишаһ, ике хезмәтчесенең һәрберсенә егерме дүрт алтын биреп, үзенең ике ай ераклыктагы хуҗалыгындагы йортына, шунда яшәп торсыннар өчен җибәрә. Аларга ул шулай ди: "Бу 24 алтыныгызны юлга һәм билетка сарыф итегез. Һәм анда да үзегезгә кирәкле әйберләр сатып алыгыз. Бер көнлек ераклыкта бер станция бар. Анда җигүле ат, автобус, пароход, поезд һәм самолет булыр. Үз акчагызга карап, кайсысын телисез, шунысына утыра аласыз".

Ике хезмәтче, шул үгетне алгач, сәфәргә чыгалар. Аларның берсе бәхетле иде; станциягә кадәр акчасының бер өлешен генә сарыф итте. Ләкин ул патша күңеленә хуш килгән шундый бер сәүдә алып барды ки, аның капиталы бердән меңгә кадәр күтәрелде. Икенче хезмәтче исә бәхетсез иде; үзенең тыңлаусыз булуы аркасында, станциягә кадәр 23 алтынын сарыф итте. Акчасын отыш уеннарында, начарлыкларга биреп бетерде. Аның бер генә алтыны калгач, иптәше аңарга әйтте: "Әй, иптәшем! Бу ерак юлда ач калырга, җәяү барырга теләмәсәң, шул калган бер акчаң белән билет ал. Безнең падишаһыбыз, әфәндебез юмарттыр, шәфкатьледер. Бәлки, сине дә самолетка утыртырлар. Барырга теләгән җиребезгә бер көндә барырбыз. Яисә бу ерак юлда ач калырга, җәяү барырга мәҗбүр булырсың".

Бу хикәядәге падишаһ - Раббыбыз, Аллаһыбыздыр. Ул ике хезмәтченең берсе - динле. Намазны үз теләге белән укучы, ә икенчесе - надан, намазсыз кешедер. 24 алтын - һәр көндәге 24 сәгатьтер. Патша йорты - җәннәттер. Хикәядәге станция исә - кабердер. Ул сәфәр - кабергә, мәхшәргә, мәңгелеккә бара торган бер сәфәрдер.

Ул юлдагы кешеләр, изге гамәлгә һәм Аллаһка якынлыклары төрлечә булулары сәбәпле, бу ерак юлны да төрлечә үтәләр. Кайбер иманлы кешеләр мең еллык юлны яшен тизлегендә, бер көндә үтәләр. Кайберләре илле мең еллык юлны хыял тизлегендә, бер көндә узалар. Коръәне Кәримдә бу мәсьәлә турында ике аять бар.

Бу хикәядәге билет - намаздыр. Биш вакыт намаз уку өчен бер сәгать вакыт җитә. Тәүлекнең 23 сәгатен шул вакытлыча булган дөнья мәшәкатьләренә сарыф итеп, бер сәгатьне мәңгелеккә, ягъни ахирәттәге мәңгелек җәннәт тормышына сарыф итмәгән кеше, әлбәттә, бик күп акылсызлык һәм үзенә золым, зарар эшләгән булыр. Чөнки, әгәр меңләгән, миллионлаган кешеләр катнашкан бер лотерея уены оештырылса, ул лотореяда җиңеп чыгу ихтималы миллионнан бер генә проценттыр. Ә надан кешеләр үзләренең капиталларын шул уенга сарыф итәләр һәм бу начар эшне акыллылык санап эшлиләр. Соңра 24 сәгатьнең бер сәгатен, йөздән туксан тугыз процент ихтимал белән эшләнергә тиешле сәүдәгә, ягъни намазга бирмичә, алар зур бер акылсызлык эшләгән булырлар.

Чынлап та намазда рухның һәм кальбнең рәхәтлеге бардыр. Ул гәүдәгә дә авыр эш түгел. Һәм дә намаз укыган кешенең бөтен хәләл гамәлләре, ягъни дөнья эшләре дә изге ният белән гыйбадәт булып саналыр; шуның белән ул кеше үзенең бөтен гомерен изге гыйбадәткә биргән булыр, дөньядагы яшәвен мәңгеләштерер.